КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 май г.Казань № 393

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау муниципаль комиссияләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 февраль, 66 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 670 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау муниципаль комиссияләре турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Муниципаль районда бер муниципаль комиссия төзелә. Шәһәр округында бер муниципаль комиссия оештырыла. Шәһәр округында, башкарыла торган эш күләмен исәпкә алып, шәһәр округының административ-территориаль бүленеше нигезендә өстәмә муниципаль комиссияләр булдырыла.»;

2.3 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль комиссия белгечләре саны бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымта нигезендә билгеләнә.»;

Нигезләмәгә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау муниципаль комиссияләре турындагы нигезләмәгә
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 15 май, 393 нче
карары редакциясендә)

## Муниципаль комиссия белгечләре саны

| Шәһәр округы (шәһәр округының бер өлеше) | | Республика әһәмиятендәге шәһәр административ үзәге булган муниципаль район | | Муниципаль район | |
|---|---|---|---|---|---|
| балигъ булмаганнар саны, кеше* | балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре белгечләренең норматив санын исәпләү | балигъ булмаганнар саны, кеше* | балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре белгечләренең норматив санын исәпләү | балигъ булмаганнар саны, кеше* | балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре белгечләренең норматив санын исәпләү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 11 000 гә кадәр (11 000 не кертеп) | бер вазыйфа (җаваплы сәркатип) | 11 000 гә кадәр (11 000 не кертеп) | бер вазыйфа (җаваплы сәркатип) | 7 000 гә кадәр (7 000 не кертеп) | бер вазыйфа (җаваплы сәркатип) |
| 11 001 дән 22 000 гә кадәр (22 000 не кертеп) | ике вазыйфа (җаваплы сәркатип һәм белгеч) | 11 001 дән 22 000 гә кадәр (22 000 не кертеп) | ике вазыйфа (җаваплы сәркатип һәм белгеч) | 7 001 дән 14 000 гә кадәр (14 000 не кертеп) | ике вазыйфа (җаваплы сәркатип һәм белгеч) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 22 000 нән артык | түгәрәкләүнең түбәндәге төрен кулланыны исәпкә алып, шәһәр округы территориясендә даими яшәүче һәр 11 000 балигъ булмаганнар өчен бер белгеч вазыйфасы: 0,49 дан кимрәк саннар – исәпкә алынмый, 0,5 тән зуррак саннар 1,0 гә кадәр түгәрәкләнә, шул исәптән муниципаль комиссияләрнең берәр җаваплы сәркатибе | 22 000 нән артык | түгәрәкләүнең түбәндәге төрен кулланыны исәпкә алып, республика әһәмиятендәге шәһәр административ үзәге булган муниципаль район территориясендә даими яшәүче һәр 11 000 балигъ булмаганнар өчен бер белгеч вазыйфасы: 0,49 дан кимрәк саннар – исәпкә алынмый, 0,5 тән зуррак саннар 1,0 гә кадәр түгәрәкләнә, шул исәптән бер җаваплы сәркатип вазыйфасы | 14 000 нән артык | түгәрәкләүнең түбәндәге төрен кулланыны исәпкә алып, муниципаль район территориясендә даими яшәүче һәр 7 000 балигъ булмаганнар өчен бер белгеч вазыйфасы: 0,49 дан кимрәк саннар – исәпкә алынмый, 0,5 тән зуррак саннар 1,0 гә кадәр түгәрәкләнә, шул исәптән бер җаваплы сәркатип вазыйфасы |

*Агымдагы финанс елына кадәрге елның 1 гыйнварына балигъ булмаганнарның федераль статистика күзәтүе мәгълүматлары буенча саны.